ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САЛИХОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САЛИХ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.03.2023 г. с.Новые Чути № 5

Баулы муниципаль районының «Салих авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гражданнарының үзара салым чараларын җыю тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы

Законы, Салих авыл җирлеге Уставы нигезендә, гражданнар җыенында кабул

ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында, Баулы муниципаль районы

Салих авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАРЫ:

1. Баулы муниципаль районының «Салих авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гражданнарының 1 нче кушымта нигезендә үзара салым чараларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

З.С. Галләметдинов